ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.10.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2034**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча комиссия төзү турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 августындагы 1594 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 августындагы 1594 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә, аерым алганда-3.3 һәм 4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.3 Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгару, тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә.
4.5 Законнар нигезендә, 4.4 пунктта күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча, карар кабул ителә, ул беркетмәдә чагылдырыла».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы (http:zelenodolsk.tatarstan.ru) составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин